КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 21 май г.Казань № 413

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 31 октябрь, 965 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1262 нче; 2019 ел, 6 май, 380 нче; 2009 ел, 11 июль, 565 нче; 2019 ел, 28 август, 714 нче; 2019 ел, 2 ноябрь, 1008 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1278 нче; 2020 ел, 16 апрель, 294 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

VII бүлектә:

1 нче пунктның бишенче абзацында «сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Тәрбияләнүчеләрнең (белем алучыларның) аерым категорияләре белән эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр кайбер белем бирү оешмаларында мәгариф хезмәткәрләренә бирелә.»;

7.1 нче пунктта:

беренче абзацта «сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

унберенче абзацта «сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

7.2 нче пунктның беренче абзацында «сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

15 нче таблица исемендә «сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтаның «Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Берлегенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының стимуллаштыру характерындагы түләүләрне бирә торган ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегендәге 2 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.6 нчы пунктча өстәргә:

| | |
|---|---|
| «2.6. | «Мәгариф отличнигы» значогы; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

III бүлекнең 2 нче пунктында «беренче – икенче төркем белән» сүзләрен «бер – ике төркем белән» сүзләренә алыштырырга;

V бүлекнең 6 нчы пунктына түбәндәге эчтәлекле уникенче абзац өстәргә:

«Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларындагы структур бүлекчәләрнең педагогик хезмәткәрләре һәм җитәкчеләре вазыйфаларына караган һөнәри квалификация төркемнәрендәге 2020 елның 1 гыйнварына кадәр ике айдан өч яшькә кадәрге балалар өчен ике яшьлек төркемнәрдә, өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балалар өчен өч яшьлек төркемнәрдә хезмәт күрсәткән хезмәткәрләргә хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 ел, 2 июль, 546 нчы карары үз көченә кергән көн алдыннан килгән көнгә түләнә торган күләмдә хезмәтнең катлаулылыгын саклауны исәпкә алып башкарыла.»;

әлеге нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтаның «Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Берлегенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегендәге 2 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.6 нчы пунктча өстәргә:

| | |
|---|---|
| «2.6. | «Мәгариф отличнигы» значогы; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы өстәмә белем бирүче мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә теркәлгән кушымтаның 1 нче таблицасындагы «Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Берлегенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 2.7 нче пунктча өстәргә:

| | |
|---|---|
| «2.7. | «Мәгариф отличнигы» значогы; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

V бүлекнең 2 нче пунктындагы бишенче абзацында «300» саннарын «550» саннарына алыштырырга;

әлеге нигезләмәгә теркәлгән 2 нче кушымтаның 1 нче таблицасындагы «Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Берлегенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегенең 2 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.6 нчы пунктча өстәргә:

| | |
|---|---|
| «2.6. | «Мәгариф отличнигы» значогы; |

әлеге карар белән расланган Югары белем бирүнең белем бирү программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын гамәлгә ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмалары һәм Татарстан Республикасы өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә теркәлгән кушымтаның «Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Берлегенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство бүләкләре» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле пунктчалар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «1.14. | Россия Федерациясенең мәгариф өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.15. | Россия Федерациясенең балалар һәм яшьләрне тәрбияләү өлкәсе мактаулы хезмәткәре». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин